ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 85

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«26» 05 2014

**Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында**

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә (алга таба – ТР ДТИ) кадрлар составы белән эшләүне алга таба камилләштерү максатларында, 2004 елның 27 июленнән 79-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль закон, 2003 елның 16 гыйнварыннан 3-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законы, 2005 елның 1 февраленнән “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында” 112 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, ТР ДТИ югары профессиональ кадрлар составы белән комплектлау һәм кадрлар резервын формалаштыру максатларында **б о е р ы к б и р ә м**:

1. Кушымта булып килүче түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне (1 кушымта).

1.2. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырылучы документлар һәм материаллар исемлеген (2 кушымта).

2. Кадрлар бүлегенә (И.Н. Никитинага) түбәндәгеләрне тәэмин итүне йөкләргә:

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаларны биләүгә конкурслар үткәрү буенча ТР ДТИ конкурс комиссиясе эшчәнлеген;

эксперт хезмәтләрен күрсәтүгә килешүнең типлаштырылган формасы нигезендә бәйсез экспертлар белән эксперт хезмәтләрен күрсәтүгә килешүләр төзүне.

3. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (О.Н. Пресняковага) конкурсларны үткәрүгә һәм Россия Федерациясе законнары һәм конкурсларны үткәрү өчен эксперт хезмәтләрен күрсәтүгә төзелгән килешүләр нигезендә бәйсез

экспертларның хезмәте өчен түләүгә акча чараларын бүлеп бирүне алдан карарга һәм чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Хокукый идарәнең юридик бүлегенә (Н.Н.Воронская) әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юлларга.

5. “Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрү турында”гы 18.01.2008 ел, 01 номерлы ТР ДТИ боерыгын көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башлык** **С.А.Крайнов**

Татарстан Республикасы Дәүләт
торак инспекциясенең 2014 елның 26
маендагы 85 номерлы боерыгына
1 кушымта

**Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Нигезләмә Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә (алга таба – ТР ДТИ) дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс үткәрүнең тәртибен һәм шартларын билгели. Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс (алга таба - конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә булган тигез мөмкинлегенә карата конституциячел хокукын, һәм шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. ТР ДТИ граждан хезмәтенең вакант вазыфасын биләүгә карата конкурс (алга таба - конкурс) 2004 елның 27 июленнән “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 79-ФЗ номерлы Федераль закон), 2005 елның 1 февраленнән “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында” 112 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба - Указ), 2003 елның 16 гыйнварыннан “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында” 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә үткәрелә.

1.3. Конкурс Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы – баш дәүләт торак инспекторы (алга таба - Башлык) карары буенча, граждан хезмәтенең 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы нигезендә конкурс нигезендә биләнергә мөмкин булган вакант (граждан хезмәткәре тарафыннан биләнмәгән) вазыйфасы булган очракта игълан ителә.

1.4. Гражданның граждан хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына керү) өчен граждан хезмәтенә алынуы яки граждан хезмәткәренең башка граждан хезмәте вазыйфасын биләве, әгәр дә бүтәне законда карламаган булса, конкурс нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла. Конкурс граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның граждан хезмәте вазыйфасына карата куелган квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүдән гыйбарәт.

79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы нигезендә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

билгеле срокка Татарстан Республикасы граждан хезмәтенең биләнә торган “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләрендәге вазыйфа

вәкаләтләренә билгеләгәндә;

ашыгыч дәүләт контрактын төзегәндә;

79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясының 2 өлеше, 31 статьясының 1 өлеше, 60.1 статьясының 9 өлеше белән каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәтендәге кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.5. Конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

ТР ДТИ боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча, вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны файдалануга бәйле булган граждан хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

Башлык карары буенча, граждан хезмәтенең кече граждан хезмәте вазыйфалары төркеменә караучы вазыйфасына билгеләгәндә.

1.6. 18 яшен тутырган, Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына карата куелган квалификация таләпләренә туры килүче Россия Федерациясе гражданнары конкурста катнашу хокукына ия.

Гомуми нигезләрдә граждан хезмәткәре, конкурсны үткәрү чорында нинди вазыйфа биләвенә карамастан, конкурста катнашырга хокуклы.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарының сәләтләренә һәм һөнәри әзерлекләренә ярашлы рәвештә дәүләт хезмәтенә булган тигез мөмкинлекле булуга карата хокукларын, һәм шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсә алу хокукларын тәэмин итү;

федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының аерым норматив-хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүче һәм конкурста катнашуга кертелүче кандидатлар арасыннан граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата аеруча туры килүче кандидатларны сайлап алу;

кадрлар резервын формалаштыру.

1.8. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителүче бурычлар:

барлык кандидатларга да конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәгәндә тигез шартлар булдыру;

кандидатларны объектив профессиональ яктан әһәмиятле критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм дәлилләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән конкурста катнашучылар арасыннан граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы таләпләренә туры килүче затларны ачыклау.

## 2. КОНКУРС КОМИССИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУНЫҢ ҺӘМ ЭШЕНЕҢ ТӘРТИБЕ

2.1. Конкурсны үткәрү өчен Башлык боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе оештырыла.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырышны үткәрү датасын билгели һәм аның көн кадагын раслый, комиссия утырышларына рәислек итә һәм тиешле документларны имзалый. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан конкурс процедураларын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем составы раслана.

Конкурс комиссиясе сәркатибе комиссиянең эшен (гаризаларны теркәү, кабул итү, эшләрне формалаштыру, комиссия беркетмәләрен алып бару һәм конкурс комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү буенча башка функцияләрне) тәэмин итә.

2.4. Конкурс комиссиясе составына эшкә алучының вәкиле һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләтләнгән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре бүлегеннән, юридик (хокукый) бүлекчәдән, граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрелүче бүлекчәдән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, ТР ДТИ каршындагы Иҗтимагый совет вәкиле, һәм шулай ук ТР ДТИ Башлыгы гаризасы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар - әлеге экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә, граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр буларак чакырылучы фәнни, белем бирү һәм башка оешмаларның вәкилләре керә.

Вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге әгъзаларның гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителүче карарларга тәэсир итәрдәй мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге булмаслык итеп оештырыла.

2.6. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына кимендә ике кандидат булганда үткәрелә.

Конкурс комиссиясенең утырышы анда барча әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.7. Конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

аны үткәрү өчен кирәкле булган методик һәм башка материалларны раслау турында;

конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатларның исемлеген раслау турында;

конкурс процедураларын үткәрү нәтиҗәләре буенча төзелгән рейтингта беренче урынны алган кандидатларны конкурсның җиңүчеләре итеп тану турында;

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаларны биләү өчен ТР ДТИ кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатларның исемлеген формалаштыру турында.

2.8. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясенең карарлары утырышта катнашкан әгъзаларының гади күпчелеге тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч санала. Кабул ителгән карар белән ризалашмаганда

конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы үз фикерен җиткерә ала, ул комиссия утырышының беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы тарафыннан имзалана.

2.9. Конкурста катнашучыларга карата конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү өчен таләпләргә аеруча туры килә, граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү өчен тәкъдим ителә;

граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата куелган таләпләргә туры килә, ТР ДТИ кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим ителә;

граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата куелган таләпләргә туры килми.

2.10. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә һәм аны граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләүгә яисә мондый билгеләүдән баш тартуга нигез булып санала.

Конкурс комиссиясе шулай ук граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурста җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны ТР ДТИ кадрлар резервына кертү турында киңәш рәвешендәге карар кабул итәргә хокуклы.

Әгәр дә конкурс комиссиясе тарафыннан граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурста җиңмәгән кандидатны ТР ДТИ кадрлар резервына кертү карары кабул ителсә, ул очракта, аталган затның ризалыгы белән, аны граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы караган шул ук төркемдәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен ТР ДТИ кадрлар резервына кертү турында ТР ДТИ боерыгы чыгарыла.

2.11. Конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителүче карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе (әлеге Нигезләмәгә 1 номерлы кушымта) белән рәсмиләштерелә, ул комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, сәркатибе һәм утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.12. Конкурс процедураларын, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен эшләү һәм әзерләү буенча эшче документларның эчтәлеге, конкурс биремнәрендәге сорауларның һәм темаларның исемлеге конкурс тәмамланганчыга кадәр хезмәт файдалануындагы мәгълүмат булып санала.

2.13. Конкурс үткәрүне оештыруны һәм тәэмин итүне, конкурс комиссиясенең эшен турыдан-туры ТР ДТИ кадрлар бүлеге башкара.

## 3. КОНКУРСТА КАТНАШУЧЫЛАР

3.1. ТР ДТИ граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата кандидатларга куелган таләпләргә җавап бирүче һәм билгеләнгән вакытка кирәкле барлык документларны тапшырган гражданнар (алга таба - кандидатлар) конкурста катнашуга кертелә.

3.2. ТР ДТИ граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) кандидатларга карата куелган таләпләр, һәм шулай ук ТР ДТИ граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырылучы документлар һәм материаллар исемлеге ТР ДТИ рәсми сайтында “Кадр документлары, вакансияләр”: “Документлар”: “ТР ДТИ вакант вазыйфаларын үтәүгә карата конкурста катнашу өчен документлар”

бүлегендә урнаштырыла. Документларның исемлеге Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтен регламентлаучы законнары нигезендә төзелгән.

3.2.1. Конкурста катнашырга теләк белдерүче Россия Федерациясе гражданы түбәндәге документларны ТР ДТИ тапшыра:

шәхси гариза;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы әмернамәсе белән расланган формада, фотосурәтен теркәп, үз кулыннан тутырылган һәм имзаланган анкета;

паспорт яки аны алмаштыручы документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

кирәкле булган һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте белән рәсмиләштерелгән күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан гайре), яки гражданның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслый торган бүтән документлар;

белем алу һәм квалификация турындагы документларның, һәм шулай ук гражданның ихтыяры белән нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан рәсмиләштерелгән өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификацияне үстерү яки алуны раслаучы документларның, фәнни дәрәҗә бирелү турындагы документларның күчермәләре;

гражданда граждан хезмәтенә алынуга яки аны үтүгә комачау итүче авыруның булмавы турында документ;

федераль законнарда каралган башка документлар.

3.2.2. ТР ДТИ граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурста катнашырга теләк белдергән ТР ДТИ граждан хезмәтендәге вазыйфаны биләүче граждан хезмәткәре гаризаны ТР ДТИ Башлыгы исеменә тапшыра.

ТР ДТИ граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурста катнашырга теләк белдергән, башка дәүләт органында граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре ТР ДТИ Башлыгы исеменә гариза һәм, фотосурәтен теркәп, граждан хезмәткәре граждан хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан имзаланган һәм рәсмиләштерелгән, үз кулы белән тутырылган анкетаны ТР ДТИ тапшыра.

3.3. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына карата куелган квалификация таләпләренә туры килмәве, һәм шулай ук дәүләт граждан хезмәтенә керүгә һәм аны үтүгә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында каралган чикләүләргә бәйле рәвештә граждан (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми (әлеге Нигезләмәгә 3 номерлы кушымта).

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.1 һәм 3.2.2 пунктларында күрсәтелгән документлар ТР ДТИ һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация системасында дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында аларны кабул итү турындагы игълан урнаштырылган көннән башлап 21 көн эчендә ТР ДТИ тапшырыла.

3.5. Документларны нигезле сәбәпләрсез вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итеп алудан баш тартуга нигез булып тора.

3.6. Документларны нигезле сәбәпләр белән вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда ТР ДТИ Башлыгы аларны кабул итүнең вакытын кичектерергә хокуклы.

3.7. Конкурста катнашуга кертелмәгән граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һәм конкурста катнашучы кандидатларның документлары аларга язма гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел эчендә кире кайтарып бирелергә мөмкин. Бу вакыт узганчыга кадәр документлар ТР ДТИ архивында саклана, аннан соң юк ителә.

3.8. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурсны уздыру урынына килү һәм китү, торак бинаны вакытлыча файдалануга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) кандидатларның шәхси хисабыннан каплана.

## 4. КОНКУРСЛАРНЫ ҮТКӘРҮНЕҢ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларына каршы килмәүче ысуллар белән бәяләүгә нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары ТР ДТИ граждан хезмәте вазыйфаларына карата куелучы квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә башкарыла.

Нәтиҗәләр кандидатларның баллар буенча төзелгән исемлеге (рейтингы) рәвешендә бирелә.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта ТР ДТИ һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турында игълан, һәм шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла: граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаның исеме, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга карата куелучы таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, әлеге Нигезләмәнең 3.2.1 һәм 3.2.2 пунктлары нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итүнең тәмамлану вакыты, конкурсны үткәрүнең уйланылган вакыты, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар. Конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турында игълан һәм конкурс турындагы мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта да басылырга мөмкин.

4.4.2. Беренче этапта конкурс комиссиясе:

шәхси әңгәмә, анкеталаштыру, төркемле дискуссияләр үткәрү, реферат яздырту яки кандидатлар дәгъва кылган граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы буенча бурычларны үтәүгә бәйле сораулар буенча тест үткәрүне кертеп, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын кулланып, конкрет конкурс процедураларын билгели;

конкурсны үткәрү шартлары турында граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарга мәгълүмат бирә һәм консультацияли;

дәгъвачылардан алынган гарызнамәләр буенча конкурс документларын бирә;

дәгъвачыларның куелган таләпләргә туры килү-килмәвенә башлангыч бәя бирә.

4.4.3. Конкурс комиссиясенең сәркатибе, конкурс комиссиясе утырышын үткәрүгә биш эш көне калган вакыттан соңармыйча, конкурс комиссиясенең барча әгъзаларына конкурста катнашучылар турында мәгълүмат тапшыра.

4.4.4. ТР ДТИ граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына керүгә) дәгъвачылар тарафыннан тапшырылган документларны тикшергәннән соң конкурс комиссиясе гражданнарны (граждан хезмәткәрләрен) конкурста катнашуга кертү яки дәлилле баш тарту турында карар чыгара.

Дәгъвачыларның тикшерелгән документлары һәм конкурс комиссиясенең тәкъдиме конкурсның икенче этабын үткәрү турындагы карарны кабул итү өчен ТР ДТИ Башлыгына тапшырыла.

4.4.5. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы килүче шартлар ачыкланганда, аңа кадрлар бүлеге тарафыннан язма формада конкурста катнашуга кертелмәвенең сәбәпләре турында карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә хәбәр ителә (әлеге Нигезләмәгә 2 номерлы кушымта).

4.4.6. Конкурста катнашуга кертелмәгән вакант вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы әлеге карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылуга хокуклы.

4.4.7. Конкурсның беренче этабы тәмамлану өчен билгеләнгән таләпләргә туры килүче кимендә ике кандидатның булуы шарт булып тора, бу алга таба кандидатларны сайлап алу мөмкинлеген бирә.

Куелган таләпләргә иң күп дәрәҗәдә туры килүче һәм алга таба конкурста катнашуга тәкъдим ителгән кандидатларның конкурс комиссиясе карары белән расланучы исемлеген төзү беренче этап нәтиҗәсе булып тора.

Эшкә алучының вәкиле, конкурсның икенче этабы башланырга 15 көн калган вакыттан соңармыйча, конкурста катнашуга кертелгән гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) аны үткәрүнең датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр итә.

4.4.8. Конкурсның икенче этабы тест сынаулары һәм конкурс комиссиясе әгъзалары белән шәхси әңгәмәләр рәвешендә үткәрелә.

4.4.9. Кандидатларны тест аша сынау язма рәвештә үткәрелә. Конкурс комиссиясе тест сынаулары өчен сораулар исемлеген төзи, һәм шулай ук дөрес булмаган җавапларның чик күләмен (яки процент өлешен) раслый. Дөрес булмаган җавапларның мөмкин күләме 25 проценттан артык була алмый.

Сорауларның исемлеге гомуми танышу өчен мөмкин булырга тиеш. Тест сораулар исемлеге нигезендә төзелә һәм конкурста катнашучының түбәндәгеләрне белүен тикшерүне тәэмин итәргә тиеш:

Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен;

федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын;

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарын;

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе турындагы нигезләмәне;

граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаның вазыйфаи регламентын;

структур бүлекчә эшчәнлеге юнәлеше буенча норматив-хокукый актларны.

Тест 50дән артык булмаган сораудан торырга тиеш.

Дөрес җаваплар тигез күләмдә булган очракта катнашучыларга, җавап бирүнең төгәл вакытын билгеләп, өстәмә тестлар бирелә.

4.4.10. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе граждан хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча башка вазыйфаи регламент нигезләмәләреннән, һәм шулай ук әлеге Нигезләмә һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнары белән билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

4.5. Конкурс комиссиясе тарафыннан әзерләнгән граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) кандидатларның рейтингы икенче этап нәтиҗәсе һәм шул ук вакытта конкурсның ахыргы нәтиҗәләре булып санала.

Конкурс нәтиҗәләрен чыгару һәм граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата кандидат турындагы карарны кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

барлык конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре буенча кандидатлар алган бәяләү критерийлары баллары суммасы;

конкурс комиссиясе конкурс җиңүчесе турындагы карарны, һәм шулай ук ТР ДТИ кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатларның исемлекләрен раслый.

4.6. Әгәр дә конкурсны үткәрү нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең конкурс игълан ителгән вакант вазыйфасы буенча кирәкле таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурсны үткәрү турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.7. ТР ДТИ Башлыгы яңа конкурс үткәрү турында яисә вакант вазыйфаны биләү өчен куелган таләпләргә аеруча туры килүче конкурста катнашучыны һәм конкурста катнашып иң күп балл җыючыны максималь сынау срогы белән граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү турында карар кабул итә.

4.8. Әгәр дә конкурста ике яки аннан да күбрәк катнашучы тигез күләмдә балл җыйса, конкурс комиссиясе рәисенең фикере хәлиткеч санала.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре конкурс комиссиясе карары белән рәсмиләштерелә, ул конкурс комиссиясендә рәислек итүче, сәркатип һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана. Шул ук вакытта конкурс комиссиясенең карарында граждан хезмәте вазыйфасына

беренче тапкыр алынган граждан өчен сынау срогының озынлыгы буенча тәкъдим бирелергә мөмкин.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча ТР ДТИ Башлыгының конкурста җиңүчене граждан хезмәтенең вакант вазыфасына билгеләү турында карары чыгарыла, һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Шул ук вакытта вазыйфалар номенклатурасы нигезендә конкурста җиңүчене вазыйфага билгеләүгә тәкъдим иткәндә, Башлыкка мәҗбүри тәртиптә конкурс комиссиясенең карары һәм конкурс комиссиясе тарафыннан мондый карарны кабул итүгә нигез булган материаллар тапшырыла.

4.11. Конкурс нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр кандидатларга ул тәмамланганнан соң 7 көнлек срокта язмача рәвештә җиткерелә. Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат шулай ук ТР ДТИ һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында урнаштырыла.

4.12. Кандидат конкурс комиссиясе карарын законнарда каралган тәртиптә шикаять кылырга хокуклы.

Татарстан Республикасы Дәүләт
торак инспекциясендә дәүләт граждан
хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына керүгә) конкурс үткәрү
турында нигезләмәгә
1 кушымта

# КОНКУРС КОМИССИЯСЕ БЕРКЕТМӘСЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең конкурс комиссиясе утырышында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендәге дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) конкурс сайлап алуы үткәрелде

________________________________________________________________
(биләнүче вакант вазыйфаның исеме)

________________________________________________________________
(структур бүлекчә исеме)

Утырышта катнашты ___ , алар арасыннан конкурс комиссиясе әгъзасы ____.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

1. ________________________________________"риза" _____, "каршы" _______.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

2. . ________________________________________ "риза" _____, "каршы" _______.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

3. . ________________________________________ "риза" _____, "каршы" _______.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча

________________________________________________________________
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

комиссия әгъзаларыннан иң күп тавыш җыйды, бу тавыш бирүдә катнашкан комиссия әгъзалары санының ______процентын тәшкил итә.

Конкурс комиссиясе рәисе ________________________________________
(имза) (имзаның тәгъбирләнеше)

Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары ________________________________________
(имза) (имзаның тәгъбирләнеше)

Конкурс комиссиясе сәркатибе ________________________________________
(имза) (имзаның тәгъбирләнеше)

Конкурс комиссиясе әгъзалары ________________________________________
(имза) (имзаның тәгъбирләнеше)

________________________________________
(имза) (имзаның тәгъбирләнеше)

________________________________________
(имза) (имзаның тәгъбирләнеше)

Конкурсны үткәрү датасы "__" ________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт
торак инспекциясендә дәүләт граждан
хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына керүгә) конкурс үткәрү
турында нигезләмәгә
2 кушымта

**Хөрмәтле ______________!**

Сезнең Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендәге дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына (кадрлар резервына керүгә) карата конкурста катнашуга кертелмәвегез турында хәбәр итәм

_______________________________________________________________

(граждан вазыйфасы, бүлек исеме)

түбәндәгеләр сәбәпле*:

а) Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаның квалификация таләпләренә туры килмәү;

б) дәүләт граждан хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында каралган чикләүләр;

в) документларны вакытында тапшырмау (аларны нигезле сәбәпләрсез тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру);

г) тикшерү барышында гражданның дәүләт граждан хезмәтенә керүенә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каршы килүче шартлар ачыклану.

Документлар Сезгә язма гариза нигезендә түбәндәге адрес буенча кайтарылырга мөмкин:

420111, Казан ш., З. Кызыл ур., 15/9 йорт, Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе, кадрлар бүлеге, телефон: 236-93-66.

Инспекция
Башлыгы (Ф.И.А.) ________________

* хатта җавапка туры килә торган вариант күрсәтелә (а-г)

Татарстан Республикасы Дәүләт
торак инспекциясендә дәүләт граждан
хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына керүгә) конкурс
үткәрү турында нигезләмәгә
3 кушымта

**Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата кандидатларга куелган таләпләр**

1. Гомуми таләпләр

1. 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү өчен кирәкле булган федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирүче Россия Федерациясе гражданнары һәм шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләре конкурста катнашу хокукына ия.

2.Граждан конкурста катнашуга түбәндәге очракларда кертелми:

1) законлы көченә кергән суд карары белән аны эшкә яраксыз яки эшкә яраклылыгы чикләнгән дип тану;

2) законлы көченә кергән суд карары буенча аны дәүләт хезмәте вазыйфасы (дәүләт хезмәте) буенча вазыйфаи бурычларны башкару мөмкинлеген калдырмаучы җәзага тартканда, һәм шулай ук федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә акланмаган яки үтәлмәгән суд хөкеме булганда;

3) дәүләт серен яки федераль закон белән саклануучы башка серне тәшкил итүче мәгълүматларга үтеп керүне рәсмиләштерү процедурасын үтүдән баш тартканда, әгәр дә граждан дәгъвалык иткән граждан хезмәте вазыйфасын биләү буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый мәгълүматларны файдалануга бәйле булса;

4) медицина оешмасы бәяләмәсе белән расланган, граждан хезмәтенә керүгә каршы килүче авыруы булганда;

5) граждан хезмәткәре белән якын туганлыкта яки үзгәлектә булу (ата-анасы, тормыш иптәше, балалары, ир туганнары, кыз туганнары, һәм шулай ук тормыш иптәшләренең ир туганнары, кыз туганнары, ата-аналары һәм балаларының тормыш иптәшләре), әгәр дә граждан хезмәте вазыйфасын биләү турыдан-туры буйсынуга яки берсенең икенчесен контрольдә тотуына бәйле булса;

6) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яки башка дәүләт гражданлыгын алу;

7) башка дәүләт (башка дәүләтләр) гражданлыгына ия булу, әгәр дә Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башкасы каралмаса;

8) граждан хезмәтенә кергәндә ялган документлар яки белә торып ялгыш мәгълүматлар тапшыру;

9) граждан хезмәтенә кергәндә 2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән мәгълүматларны тапшырмау яки керемнәр турында, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белә торып ялгыш белешмәләр тапшыру;

10) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү турында яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында 2004 елның 27 июленнән “Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында”гы 79-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 28 декабреннән “Коррупциягә каршы көрәш турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәү очракларында эшкә алучының вәкиле тарафыннан граждан хезмәткәренә карата ышаныч бетү;

11) чакыру комиссиясе бәяләмәсе нигезендә законлы нигезләр булмый торып аны чакыру буенча хәрби хезмәтне үтмәгән дип тану (контракт буенча хәрби хезмәт үткән гражданнардан кала).

## 2. Квалификация таләпләре

3. Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) белеменә һәм стажына яки граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре:

1) граждан хезмәте вазыйфаларының төп төркемнәрендәге “җитәкчеләр” категорияләре – югары белем булу, граждан хезмәтенең алдынгы яки өлкән төркемнәрендәге вазыйфаларында кимендә ике еллык стаж яки белгечлек, әзерлек юлламасы буенча кимендә өч еллык стаж;

граждан хезмәтенең алдынгы төркемнәрендәге “җитәкчеләр” категорияләре - югары белем булу, граждан хезмәтенең өлкән һәм кече төркемнәрендәге вазыйфаларында кимендә бер еллык стаж яки белгечлек, әзерлек юлламасы буенча кимендә ике еллык эш стажы;

2) граждан хезмәтенең алдынгы төркемендәге “белгечләр” категорияләре - югары белем булу, граждан хезмәтенең өлкән яки кече төркемнәрендәге вазыйфаларында кимендә бер еллык стаж яки белгечлек, әзерлек юлламасы буенча кимендә ике еллык эш стажы;

3) граждан хезмәтенең өлкән төркемендәге “белгечләр” категорияләре – югары белем булу. Граждан хезмәтенең өлкән төркемендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен граждан хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юлламасы буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре куелмый.

4) граждан хезмәтенең алдынгы төркемендәге “тәэмин итүче белгечләр” категорияләре - югары белем булу, граждан хезмәтенең өлкән яки кече төркемнәрендәге вазыйфаларында кимендә бер еллык граждан хезмәте стажы яки белгечлек буенча кимендә ике еллык эш стажы;

5) граждан хезмәтенең өлкән һәм кече төркемнәрендәге “тәэмин итүче белгечләр” категорияләре – эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган урта һөнәри белем булу. Граждан хезмәтенең өлкән һәм кече төркемнәрендәге вазыйфаларны биләү өчен граждан хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юлламасы буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) карата квалификация таләпләре куелмый.

Граждан хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук федераль дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфаи төркемнәрендәге вазыйфаларда һәм аларга тиңләштерелгән хәрби һәм хокук саклау хезмәте вазыйфаларында, һәм шулай ук муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфалар төркемнәрендәге вазыйфаларда эшләү стажы исәпкә алына.

4. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре граждан хезмәтенең вазыйфаи регламенты белән билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Дәүләт
торак инспекциясенең 2014 елның 26
маендагы 85 номерлы боерыгына
2 кушымта

**Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата кандидатлар тарафыннан Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә тапшырылучы документлар һәм материаллар исемлеге**

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурста катнашырга теләк белдергән граждан Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә түбәндәге документларны һәм материалларны тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) фотосурәтен теркәп, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы әмернамәсе белән расланган формада анкета;

в) паспорт яки аны алмаштыручы документ күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

г) кирәкле булган һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарылган очраклардан гайре), яки гражданның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

д) гражданда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачау итүче авыруның юклыгы турында документ (№ 001-ГС/у формасы);

е) башка документлар:

мәҗбүри пенсия иминиятләве таныклыгы күчермәсе, хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарылган очраклардан гайре;

физик затның Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә куелуы турындагы таныклык күчермәсе;

хәрби исәп документларының күчермәләре – хәрби бурычлы булганнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр.

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурста катнашырга теләк белдергән, Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәре гаризаны Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе Башлыгы исеменә 20 номерлы кабинетта тапшыра.

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар

резервына керүгә) карата конкурста катнашырга теләк белдергән, башка дәүләт органында дәүләт граждан хезмәтен биләүче дәүләт граждан хезмәткәре Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе Башлыгы исеменә гариза һәм, фотосурәтен теркәп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы әмернамәсе белән расланган формалы, үз кулы белән тутырылган, имзаланган һәм дәүләт граждан хезмәткәре дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан рәсмиләштерелгән анкетаны тапшыра.

Документлар игълан бастырылган көннән башлап 21 көн дәвамында түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Казан ш., Зур Кызыл ур., 15/9, кадрлар бүлеге.

Тел., факс (843) 236-93-66.

рәсми сайт: gji.tatarstan.ru.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итеп алудан баш тартуга нигез булып тора.

Нигезле сәбәпләр аркасында документларны вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда, ТР ДТИ Башлыгы аларны кабул итү вакытын кичектерергә хокуклы.